# Җаекмы, Йайыкмы?

«Безнең мирас» журналының 5нче санында Адлер Тимергалинның “Миллият сүзлеге»ндә Җаек елгасы турында шундый кызыклы җөмлә укыдым: “Башкорт телендәге *Йайык* атамасы рус теленнән алынган (аларда ул *Яик* дип атала), ягъни башкортлар бу елганы соң белгәннәр булып чыга”. Әлбәттә, моны авторның шәхси фикере дип тә кабул итәргә була, ләкин тарихи яктан да, тел ягыннан да, ичмаса география күзлегеннән дә бу фикер белән берничек тә килешергә мөмкин түгел.

Иң беренче чиратта, бу сүзнең ике тугандаш халыкта ни өчен аерылып торуына ачыклык керттик. Билгеле булганча, татар теле күп гасырлар дәвамында формалашкан, үскән, үз эченә күп төрле элементларны алган. Әйтик, сөйләм (бигрәк тә кайбер диалектларда) һәм язма телебездә кайбер сүзләрнең й-лаштырып һәм җ-лаштырып куллану очракларын әйтеп узарга була: йомырка – [җоморка], елан – [җылан]. Ахыргы сүз Казанда яшәгән урыслар  арасында билгеле булган “Зилантова гора”, «Зилантов монастырь» сүзтезмәләрендә дә теркәлеп калган һәм “Зилант” сүзенең шул татар сүзенең сөйләм формасыннан килеп чыгуы аңлашыла. Инде башкорт теленә килгәндә, аның әдәби һәм сөйләм телендә й-лаштырып сүзләрне әйтү һәм язу ешрак күзәтелә. Шуңа күрә, татарча булган “җыр” – башкортча “йыр”, татарча әйтелә һәм языла торган “җыен” башкорт телендә “йыйын” булачак. Шулай итеп татар, казакъ телләрендә җ-лаштырып әйтелгән елга исеме (тат. Җаек) башкорт телендә й-лаштырып әйтелер һәм языла (башк. Йайык).

Инде авторның “башкортлар бу елганы соң белгәннәр булып чыга” дигән фаразы шулай ук тарихи фактларга каршы килә. Башкорт халкы асылда Урал таулары тирәсендә формалашкан. Аларның этник тарихларында аерым туктамыйча (теләгән кешеләр башкорт халкы турында саллы хезмәтләр укый ала) шуны гына әйтергә телим: Урал таулары тирәсендә башкортлар элек-электән яшәгән булсалар, урыслар Көньяк Урал территориясенә һәм казакълар яшәгән далаларга соңрак килеп чыгалар. Шуңа күрә Урал тауларыннан агып чыккан елгалар турында башкортлар элегрәк белгәннәр, башкорт халык авыз иҗатында да бу яхшы күрелә. Шул исәптән XVIII гасырда көньяк-көнчыгышка барган рус колониаль хәрәкәт чорында Оренбург губерниясе территориясендә барлыкка килгән рус ныгытмалары һәм шәһәрләре, татар авыллары һәм бистәләре (Сәгыйд бистәсе – хәзерге Оренбург өлкәсе Каргалы авылы) асылда моңа кадәр башкортлар һәм казакълар яшәгән җирләрдә урнашкан була һәм моны Мәскәү, Оренбург, Петербург архивларында саклaнучы күп кенә документлар раслый. Шуңа күрә Җаек турында башкортлар һичничектә руслардан белә алмаганнар. Бәлки, киресенчә, русча билгеле булган “Яик” атамасы шул җирле халыклардан алынган да булса кирәк – башкорт “Йайык” сүзеннән.

Бу кечкенә мәкаләмдә мин хөрмәтле эзтабар, публицст-галим һәм язучы Адлер Тимергалинны берничек тә хурлыкта калдырырга, аны кимсетергә ниятем юк. Теләгем бер генә – булган хатаны төзәтү, аңа авторның да, журналны укучыларның да игътибарын җәлеп итү.

Тарих фәннәре кандидаты,
КФУ Татар халкын өйрәнү һәм тюркология кафедрасы доценты
Әскәр Гатин